**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Кама Тамагы муниципаль районынын**
**Сойки авыл жирлеге**
**Башкарма комитеты**

**Кама Тамагы районы,**
**Сойки авылы**
**тел. 8 (843) 77 36-3-38**
**РТ Камско-Устьинский район с. Сюкеево**
**ул. Колхозная дом 16а**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Исполнительный комитет**
**Сюкеевского сельского поселения**

**Камско-Устьинский район,**
**с. Сюкеево**
**тел. 8 (843) 77 36-3-38**
**РТ Камско-Устьинский район с. Сюкеево ул. Колхозная дом 16а**

---

# КАРАР

2022 елның 31 гыйнвары №2

**2022 елга Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында»Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 6964 сум 68 тиен күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы

муниципаль районының Сөйки авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 2021 елның 29 гыйнварындагы 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР Кама Тамагы районы, Сөйки ав.,Кызыл Армия ур., авыл үзәге;

- Кама Тамагы районы Сөйки авылы, Колхоз ур., 16а йорты, китапханә бинасы;

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе В.П. Никитин

Кама Тамагы муниципаль районының
Сөйки  авыл җирлеге башкарма
комитетының 2022елның 31
гыйнварындагы 2 номерлы  карарына 1
нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки  авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләрнең бәяләре

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 4173,42 |
| 3. Үлгән кешенең  мәетен (җәсәден) зиратка илтү | 593,88 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2197,38 |
| Барлыгы | 6964,68 |

Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге башкарма комитетының 2022елның 31 гыйнварындагы 2 номерлы карарына 2 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләрнең бәяләре

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 214,18 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3959,24 |
| 4. Үлгән кешенең мәетен (җәсәден) зиратка илтү | 593,88 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2197,38 |
| Барлыгы | 6964,68 |